СОВЕТ ИМЕНИ ВОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423729,Республика Татарстан, Мензелинский район, п.совхоза им.Воровского, ул. Центральная, 18

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ВОРОВСКИЙ ИСЕМЕНДӘГЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423729, Татарстан Республикасы, Минзәлә район,Воровский ис.совхоз поселогы , Үзәк урамы,18

# КАРАР

№ 1 15.10.2019 ел

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Воровский ис авыл җирлеге Советының 14.04.2014 елдагы "Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Воровский ис авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең, муниципаль вазыйфаларны башкаручы затларның вазыйфаи торышы яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәя бирү, аны сатудан алынган чараларны исәпләү һәм сату (сатып алу) турында хәбәр итү тәртибе турында"гы №1 карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы №131-ФЗ Федераль законы, 2007 елның 2 мартындагы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында"гы №25-ФЗ Федераль законы, 2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы тору турында"гы №25-ФЗ Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 9 гыйнварындагы "Аерым категориягә керүче затларның хезмәт (вазыйфаи) бурычлары беркетмәле чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә, аларда катнашу аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычлары, бүләк тапшыру һәм бәя бирү, аны сатудан алынган чараларны исәпләү һәм сату (сатып алу), бүләк алу турында хәбәр итү тәртибе турында"гы №10 Карары (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 12.10.2015 елдагы №1089 Карары редакциясендә) нигезендә, Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Воровский ис авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Воровский ис авыл җирлеге Советының 14.04.2014 елдагы "Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Воровский ис авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең, муниципаль вазыйфаларны башкаручы затларның вазыйфаи торышы яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәя бирү, аны сатудан алынган чараларны исәпләү һәм сату (сатып алу) турында хәбәр итү тәртибе турында"гы №1 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарның аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Аерым категориягә керүче затларның хезмәт (вазыйфаи) бурычлары беркетмәле чаралар, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә, аларда катнашу аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычлары, бүләкне тапшыру һәм бәя бирү, аны сатудан алынган чараларны исәпләү һәм сату (сатып алу), бүләк алу турында хәбәр итү тәртибе турында”;

1.2. Карарның 1 пунктында “вазыйфаи торыш яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу турында” сүзләрен “катнашуы аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәү белән бәйле беркетмәле чаралар, хезмәт командровкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә бүләк алу турында” сүзләре белән алыштырырга.

2. Минзәлә муниципаль районы Воровский ис авыл жирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең, муниципаль вазыйфаларны башкаручы затларның вазыйфаи торышы яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәя бирү, аны сатудан алынган чараларны исәпләү һәм сату (сатып алу) турында хәбәр итүе турындагы Нигезләмәсен яңа беркетелгән редакциядә расларга.

3. Гамәлдәге карарны “Интернет” челтәрендә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет рәисе: Один

Минзәлә муниципаль районы
Воровский ис авыл җирлеге Советы
карарына
Кушымта 1

№1 дата 15.10.2019 ел.

**Минзәлә муниципаль районының Воровский ис авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, муниципаль вазыйфаларны башкаручы затларның хезмәт (вазыйфаи) бурычлары беркетмәле чаралар, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә, аларда катнашу аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычлары, бүләкне тапшыру һәм бәя бирү, аны сатудан алынган чараларны исәпләү һәм сату (сатып алу), бүләк алу турында хәбәр итү тәртибе турында**
**Нигезләмә**

1. Гамәлдәге Нигезләмә Минзәлә муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең, муниципаль вазыйфаларны башкаручы затларның вазыйфаи торышы яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, хезмәт (вазыйфаи) бурычлары беркетмәле чаралар, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә, аларда катнашу аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычлары, бүләкне тапшыру һәм бәя бирү, аны сатудан алынган чараларны исәпләү һәм сату (сатып алу), бүләк алу турында хәбәр итү тәртибен билгели.

2. Гамәлдәге Нигезләмә максатлары өчен түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

**муниципаль вазыйфа башкаручы зат** - депутат, җирле үзидарәнең сайланган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланган вазыйфаи заты, даими (штат) нигезендә комиссиядә эшләүче, хәлиткеч тавышка ия булган һәм даими нигездә эш итүче Минзәлә муниципаль районының сайлау комиссиясе әгъзасы, Минзәлә муниципаль районының контроль-хисап органы рәисе;

**муниципаль хезмәткәр** – федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә җирле бюджет чаралары хисабыннан түләнә торган акчаларга Минзәлә муниципаль районының сайлау комиссиясе аппаратында, җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча бурычларны үтәүче гражданин;

**беркетмәле чаралар, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә алынган бүләк –** беркетмәле чараларда, хезмәт командировкаларында һәм башка рәсми чараларда аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәү максатларында күрсәтелгән чарада һәр катнашучыга бүләкләү сыйфатында тапшырылган чәчәкләр һәм кыйммәтле бүләкләрдән тыш, канцелярия әсбапларыннан тыш, бүләкләнүченең вазыйфаи хәленнән яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларыннан чыгып гамәлгә ашырыла торган физик (юридик) затлардан муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфа башкаручы заттан алынган бүләк;

**катнашу хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәү белән бәйле беркетмәле чаралар, хезмәт командровкалары һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә, бүләк алу –** вазыйфаи регламент (вазыйфаи инструкция) белән каралган эшчәнлекне

гамәлгә ашыру кысаларында, шулай ук күрсәтелгән затларның һөнәри хезмәт һәм хезмәт эшчәнлеге спецификасын һәм хокукый торыш үзенчәлекләрен билгеләүче федераль законнар һәм башка норматив хокукый актлар белән билгеләнгән очракларда, хезмәт (вазыйфаи) бурычларны үтәүгә бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәр, муниципаль вазыйфа башкаручы зат тарафыннан шәхсән яисә физик (юридик) зат аша бүләк алуы.

3. Муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфа башкаручы затлар вазыйфаи халәте яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларына бәйле рәвештә физик (юридик) затлардан бүләк алырга хокуклы түгел (катнашу аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәү белән бәйле беркетмәле чаралар, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә алынган бүләкләрдән тыш).

4. Муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфа башкаручы затлар гамәлдәге Нигезләмәдә каралган тәртиптә хезмәт (вазыйфаи) бурычларына бәйле рәвештә физик (юридик) затлардан бүләк алырга хокуклы түгел (катнашу аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәү белән бәйле беркетмәле чаралар, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алган барлык очраклар турында күрсәтелгән затлар муниципаль хезмәт уза яисә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган җирле үзидарә органына, Минзәлә муниципаль районының сайлау комиссиясенә (алга таба – җирле үзидарә органы, сайлау комиссиясе) хәбәр итәргә тиеш.

5. Кушымта нигезендә төзелгән, катнашу хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәү белән бәйле беркетмәле чаралар, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу турында хәбәр язуы бүләк алганнан соң 3 эш көненнән соңармыйча муниципаль хезмәткәр, муниципаль вазыйфа башкаручы зат муниципаль хезмәт уза яисә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган җирле үзидарә органының структур подразделениесенә, сайлау комиссиясенә (алга таба – вәкаләтле структур подразделение (вәкаләтле орган яисә оешма) тапшырыла. Хәбәр язуына бүләкнең бәясен раслаучы документлар (булган очракта) (касса чегы, товар чегы, бүләккә түләү (сатып алу) турында документ) теркәлә.

Әгәр бүләк хезмәт командировкасы вакытында алынган икән, хәбәр язуы бүләк алган зат хезмәт командировкасыннан кайткан көннән соң 3 эш көненнән соңармыйча тапшырыла.

Муниципаль хезмәткәр, муниципаль вазыйфа башкаручы затка бәйле булмаган сәбәп аркасында хәбәр язуын гамәлдәге пунктның беренче һәм икенче абзацларында күрсәтелгән срокларда бирү мөмкинлеге булмаганда, ул хата төзәтелгән көннең икенче көнненнән соңармыйча тапшырыла.

6. Хәбәр язуы ике экземплярда төзелә, аның берсе теркәлү турында билге белән хәбәр язуын тапшыручыга, икенчесе бухгалтерлык учеты турында законнар нигезендә барлыкка килгән җирле үзидарә органының, сайлау комиссиясенең активлары керү һәм чыгу буенча комиссиягә (алга таба – комиссия) җибәрелә.

7. Бәясе документлар белән расланган һәм 3 мең сумнан артмаган бүләк яисә аның бәясе муниципаль хезмәткәргә билгесез булганда, тиешле теркәү журналында хәбәр язуы теркәлгән көннән соң 5 көннән соңармыйча, кабул итү – тапшыру акты буенча саклануга кабул итүче вәкаләтле структур подразделениенең җаваплы затына тапшырыла.

8. Муниципаль вазыйфа башкаручы зат тарафыннан алынган бүләк, аның бәясенә бәйсез рәвештә, гамәлдәге Нигезләмәнең 7 пунктында каралган тәртиптә,

саклауга куелырга тиеш.

9. Кабул итү – тапшыру акты буенча бүләк тапшырылганга кадәр, Россия Федерациясе законнары нигезендә, бүләкне югалткан яисә зарарлаган өчен бүләкне алган зат җаваплылык тота.

10. Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә бүләкне бухгалтерлык учетына кабул итү максатларында, кирәк булганда комиссияне җәлеп итеп, аның бәясен билгеләү бүләкне учетка алу датасына гамәлдә булган базар бәясе яисә капма-кары кую шартларында шундый ук матди байлыкка бәя нигезендә уздырыла. Базар бәясе турында мәгълүматлар документ белән раслана, ә документ белән раслау мөмкин булмаганда – эксперт юлы белән. Әгәр бүләк бәясе 3 мең сумнан артмый икән, кабул итү – тапшыру акты буенча аны тапшырган затка кире кайтарыла.

11. Вәкаләтле структур подразделение бәясе 3 мең сумнан артып киткән билгеләнгән тәртиптә бухгалтер учетына кабул ителгән бүләкне Минзәлә муниципаль район реестрына кертүне тәэмин итә.

12. Бүләкне тапшырган муниципаль хезмәткәр, муниципаль вазыйфа башкаручы зат яллаучы (эш бирүче) исеменә бүләк тапшырылган көннән соң ике айдан да соңармыйча тиешле гариза җибәреп, аны сатып ала алалар.

Җирле үзидарә органы, сайлау комиссиясе җитәкчесе бүләк тапшырылган көннән соң ике айдан да соңармыйча тиешле күрсәтмә чыгарып, тапшырган бүләкне сатып ала ала.

13. Вәкаләтле структур подразделение гамәлдәге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгән гариза (күрсәтмә басмасы) кергән көннән соң 3 ай эчендә сату (сатып алу) өчен бүләкнең бәясенә бәя бирүне оештыра һәм бәя бирү нәтиҗәләре турында гариза биргән затка язмача формада хәбәр итә, шуннан соң бер ай эчендә гариза бирүче бәя бирү нәтиҗәсендә билгеләнгән бәя буенча бүләкне сатып ала яисә сатып алудан баш тарта.

14. Гамәлдәге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгәнчә, аңа карата гариза кермәгән бүләк җирле үзидарә органы, сайлау комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү өчен бүләкне куллануның файдасызлыгы турында комиссия чыгарган нәтиҗәне исәпкә алып, җирле үзидарә органы, сайлау комиссиясе тарафыннан файдаланылырга мөмкин.

15. Җирле үзидарә органы җитәкчесе, сайлау комиссиясе тарафыннан куллану файдасыз булган очракта, Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә торги уздыру юлы белән вәкаләтле муниципаль орган оештырган бүләкне сату һәм сату (сатып алу) өчен аның бәясенә бәя бирүне уздыру турында карар кабул ителә.

16. Гамәлдәге Нигезләмәнең 13 һәм 15 пунктларында каралганча, сату (сатып алу) өчен бүләк бәясенә бәя бирү Россия Федерациясенең бәя бирү эшчәнлеге турындагы законы нигезендә гамәлгә ашырыла.

17. Әгәр бүләк сатып алынмаган яисә сатылмаган икән, җирле үзидарә органы, сайлау комиссиясе җитәкчесе тарафыннан бүләкне кабаттан сату, яисә аны түләүсез хәйриячелек оешмасы балансына тапшыру, яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә аны юк итү турында карар кабул ителә.

18. Бүләкне сатудан (сатып алу) алынган акчалар Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә Минзәлә муниципаль районы бюджеты керемнәренә күчереләләр.

Минзәлә муниципаль районының
Воровский ис авыл жирлеге
муниципаль хезмәткәрләренең,
муниципаль вазыйфаларны башкаручы
затларның хезмәт (вазыйфаи)
бурычлары беркетмәле чаралар,
хезмәт командировкалары һәм
башка рәсми чараларга бәйле рәвештә,
аларда катнашу аларның
хезмәт (вазыйфаи) бурычлары,
бүләкне тапшыру һәм бәя бирү,
аны сатудан алынган чараларны
исәпләү һәм сату (сатып алу),
бүләк алу турында хәбәр итү тәртибе турында
Нигезләмә

**Бүләк алу турында хәбәр язуы**

______________________________________
(жирле үзидарә органының,
______________________________________
сайлау комиссиясенең
______________________________________
структур подразделениесе аталышы

дата ______________________________________

______________________________________
(ф.ис.ат.ис., башкарган вазыйфасы)

Бүләк алу турында хәбәр язуы дата "__" ________ 20__ ел.

Бүләк (ләр) алуым турында хәбәр итәм ______________________________________
(алу датасы)

______________________________________
(беркетмәле чара, хезмәт командировкасы, башка рәсми чара аталышы, уздыру урыны һәм датасы)

| Бүләк аталышы | Бүләккә тасвирлама, характеристика | Предметлар саны | Бәясе сумнарда <*> |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |
| 3. | | | |
| Барлыгы | | | |

Кушымта: ______________________________________ _____ битләрдә.
(документ аталышы)

Хәбәр язуын тапшыручы зат
_________ __________________________ "__" ____ 20__ ел.
(имза) (тулы имза)

Хәбәр язуын алучы
зат
_________ __________________________ "__" ____ 20__ ел.
(имза) (тулы имза)

Хәбәр язуларын теркәү журналында теркәү номеры ___________________

"__" _________ 20__ ел.

______________________________________
* Бүләкнең бәясен раслаучы документлар булганда тутырыла.